**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

унтугызынчы утырыш
**КАРАРЫ**

29 апрель 2022 ел **№ 124** Теләче ав.

Теләче муниципаль районы Советының 2017 елның 19 июлендәге 92 номерлы «Теләче муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Теләче муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" челтәрендә урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Теләче районы прокуратурасының 2022 елның 18 мартындагы 02-08-01-2022 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2017 елның 19 июлендәге 92 номерлы «Теләче муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Теләче муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" челтәрендә урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына (30.06.2021 ел №61 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Теләче муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Теләче муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" челтәрендә урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәгә:

- 2 пунктның "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г)җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (килешү башкарылган) акчаларны алу чыганаклары турындагы белешмәләр, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта, әгәр мондый алыш-

бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы

Н.Н. Хаҗипов